Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Макаровка торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 13 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең Макаровка торак пунктында граждannar җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Макаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2000 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны юлларны төзекләндерүгә вак таш сатып алу һәм китерү өчен тотарга.

Граждannar җыенында рәислек итүче,
Макаровка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Кудряшов